Без тарихта эзлебез

# Бостанга – биш йөз ел!

Касыйм татарлары турында шактый күп укыган, ишеткән булсам да, үзләрен барып күргән юк иде әле. Ниһаять, җай чыкты. Узган шимбә көнне БТК башкарма комитеты әһелләре белән Рязань өлкәсендәге Сасов районының Бостан авылында сабан туенда булып кайттык.

Билгеле, гадәти генә авыл сабантуе булса, Конгресс дистәдән артык кешене 760 чакырымлы юлга чыгарып җибәрмәс иде. 25 июль көнне Бостан авылы үзенең 500 еллыгын билгеләп үтте. Мәскәү дәүләтенең архив чыганакларында әлеге йомышлы татарлар авылы 1515 елның 14 декабрендә телгә алынган икән. Телгә алыну вакыты гына бу. Авылга нигез тагын да иртәрәк салынган, димәк.

- Бу вакыйганы зурлап билгеләп үтәргә булдык. Әүвәл авыл үзәгендә әлеге датаны тарихта калдыру максатында истәлек билгесе куярга дип килештек. Халыкка мөрәҗәгать итеп, 140 мең сумнан артык акча җыйдык. Кичә стелланы тантана оештырып ачтык та инде. Быелгы сабантуен да шушы күркәм юбилейга багышлап уздырабыз. Шушы көннәрдә авыл тарихына багышланган китап та чыгачак. Сентябрь аенда аны зурлап тәкъдим итәргә җыенабыз,- дип сөйләде безне каршы алган Сасов районы татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе, җирле индустриаль техникумда системалы администратор булып эшләүче Нургаяз Гарипов. Нинди чиста, матур әдәби телдә сөйләшә! дип гаҗәпләнсәк, үзебездәге Азнакай районының Буралы авылында туып үскән якташыбыз булып чыкты ул. 1985 елда Казанда КАИ тәмамлаган егетне язмыш, дөресрәге хатыны Алимә 1994 елны Сасовка китергән; хәләл җефете әлеге Бостан авылыннан икән. Алдагы көнне генә бабасын – хатынының әтисе Мөхтәрҗан Барамыковны җирләгәнгә, шактый арган иде ул. Шуңа карамастан ярты төнгә кадәр без-журналистларга авылны күрсәтеп йөрде.

Сасово сүзенең тамыры саз сүзенә кайтып кала дип аңлатты безгә

өлкәннәр. Үзләре Сасовка барып кайтасы бар әле дип сөйләшәләр. Чынлап та, янәшәдә сазлыклы урыннар бар икән. Шуңа күрә кайбер галимнәребез, сазлы җир икән сасы сүзенә дә бәйле булырга мөмкин, дип тә аңлатты бу атаманың мәгънәсен. Сасов - өлкә күләмендәге шәһәр. Индустриаль техникумнан тыш, очучылар әзерли торган училищесы белән мәгълүм ул. Халкы утыз меңнән артык. Бостан авылы белән арасы алты гына чакырым булганга һәм саладагы күмәк хуҗалык таркалып, эш урыннары калмаганга, бостанлыларның мотлак күпчелеге (750се) район үзәгендә эшли һәм яши. “Арагыз бик якын бит. Нигә авылда гына яшәмисез?”- дип сорагач: “Кыш көне юлларны кар баса, даими чистарттырып торырга техника юк,”- дип җаваплады бостанлылар. Хуҗалык җирләре буш ята дип әйтергә мөмкин бүген. Игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнергә теләгән бер эшкуар да табылмаган. “Әле 20-30 ел элек кенә өчәр-дүртәр көтү чыга иде, бүген авылда 10-15 сыер бар. Халык сөт-майны кибеттән сатып ала”,- дип авыр сулады картлар. Кайчандыр бирегә дүрт авылдан килеп белем алсалар, хәзерге вакытта башлангыч мәктәптә 6 бала укый. Кышын авылда өч йөзләп кеше яшәсә, җәйләрен  халкы кунакка кайтучылар хисабына меңнән арта. Гомумән, Рязань өлкәсендә биш меңләп татар бар икән.

Икенче көнне, сабан туе башланганчы авылдагы мәчетләрне сурәткә төшереп кайтырга булдык. 1847 елны салынган тарихи мәчетне авылдашлары – хәзерге вакытта Мәскәүдә яшәүче адвокат Әнвәр Девликамов төзекләндергән икән. Икенче яңа мәчетне салу чыгымнарын нигездә бүген Уфада яшәүче Фатиха ханым Нагаева үз җилкәсенә алган. Сабантуй мәйданында имамнар Галимҗан Ибраһимов белән Жура Тураев белән әңгәмә корып алдык. Шунысы кызык: авылда Коръән ашларын җыен дип әйтәләр икән.

- Гадәттә җыенда табынга сарык шурпасы, карабодай боткасы куела. Токмачлы ашны башка вакытта пешермиләр диярлек. Быел авылда унике ифтар мәҗлесе уздырылды,- дип сөйләде хәзрәтләр, дини мәҗлестә өстәлгә нинди

ризыклар куела, дип сораштыргач.  Сабантуй мәйданында да кунакларны сарык шулпасы, пылау белән сыйладылар.

Милли бәйрәмебез әле өченче генә мәртәбә уздырыла икән Бостан җирендә. Шуңа карамастан җирле халык яратып өлгергән аны. Авыл янәшәсендәге каенлыкта ул көнне ике меңнән артык кеше җыелган иде. Янәшәдә генә ат чабышлары уздыру өчен киң, иркен болын бар. Халыкны Рязань өлкәсе губернаторы урынбасары Шәүкәт Әхмәтов, район хакимияте башлыгы Сергей Макаров, БТК башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Рязань өлкәсе имам-мөхтәсибе Рәшит хәзрәт Балтачиев һәм башка дәрәҗәле кунаклар котлады. Бездән аермалы буларак, тәкәне ат чабышында беренче килүчегә тапшырды бостанлылар. Баш батырга өй җиһазы һәм кубок бирделәр. Татарча көрәш дигәне күбрәк ирекле көрәшне хәтерләтте. Ә менә аеруча истә калганы таш күтәрү булгандыр. Дүрт потлы ташны ике куллап баш өстенә кем күбрәк күтәрә дип ярышты пәһлеваннәр. Ике дистәдән арттыручы булмады шикелле. Ике кешенең К-700 тракторы көпчәге тартышуын тамаша кылырга да күп кеше җыелган иде. Әтәч куелган шома багана бездәгедән шактый кыскарак тоелса да, очына менеп җитү бәхете берничә егеткә генә елмайды.

Өлкәннәр нигездә татарча сөйләшсә дә, яшьләр күбрәк урысча аралаша икән дип нәтиҗә ясадык без сабан туена җыелган халыкның үзара ничегрәк аралашуын тыңлап йөргәч. Татарча укыту булмагач гаҗәп тә түгел бу. Әйтик, сабан туе оештыруга зур өлеш керткән, бәйрәм чаралары оештыруны башлап йөргән район электр челтәре директоры Линур Енгаличев, җирле янгын сүндерүчеләр җитәкчесе Рөстәм Девликамовлар үзебезчә шактый чиста сөйләшсә дә, татарча укый алмыйбыз шул, дип таныды, мин үзебездән алып килгән газеталарны тәкъдим иткәч. Һәрхәлдә сабантуй оештырырга, авыл тарихын яздырырга алынганнар икән, биредә татар рухы саклана дигән сүз бу. Безгә шунысы да кызыклы тоелды: биредә Барамыков, Канеев, Симашов, Ембулатов, Енгалычев, Енилеев, Девликамов, Клеблеев, Сакаев, Садаев

фамилияләре киң таралган икән.

- Авыл клубын төзекләндереп бетереп, монда Татар мәдәнияте үзәге ачып җибәрә алсак, балаларга татар теле һәм әдәбияты укыта башларга мөмкинлек туар, мәдәни чаралар оештырырга шартлар яхшырыр, бермә-бер артыр иде,- дип хыяллана җирле милли-мәдәни мөхтәрият җитәкчеләре. Бостанда эшләп килгән “Гөлбостан” һәвәскәрләр ансамбленең чыгышларын тыңлагач, авылны татар моңы саклый, дип нәтиҗә ясаучылар да булды арабызда.

Рәшит Минһаҗ